РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЙДАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Гагарина ул., д. 13 а, д.Айдарово, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Гагарин ур., 13 а нче йорт, Айдар авылы, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318091 ОГРН 1061675010825 ИНН/КПП 1619004436/161901001

**№ 8** **«13» август 2020 г.**

Теләче муниципаль районының Айдар авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Айдар авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районының Айдар авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Айдар авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Айдар авылы, Ленин ур., 39 нчы йорт, Айдар авыл җирлеге бинасында мәгълүмат стенды;
- Айдар авылы, Ленин ур., 32нче йорт, Айдар авылы кибете янында мәгълүмат стенды;

- Субаш авылы, М.Җәлил ур., 5 а йорт, Субаш авылы кибете янында мәгълүмат стенды.

2. Айдар авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» 2019 елның 25нче июль № 14 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Айдар авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча : Айдар авылы, Ленин ур., 39 нчы йорт, Айдар авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЙДАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Р.Р. Хаҗиев